**УКАЗ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы территориясендә дәүләт түләүсез юридик ярдәм системасында катнашучыларның үзара хезмәттәшлеге тәртибенә үзгәрешләр кертү турында**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы территориясендә дәүләт түләүсез юридик ярдәм системасында катнашучыларның үзара хезмәттәшлеге тәртибен раслау турында» 2013 елның 24 маендагы ПУ-444 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2022 елның 15 сентябрендәге ПУ-645 номерлы Указы нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасы территориясендә дәүләт түләүсез юридик ярдәм системасында катнашучыларның үзара хезмәттәшлеге тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) 2 пунктның бишенче абзацында «Адвокатлар» сүзеннән соң «һәм нотариуслар» сүзләрен өстәргә;

б) түбәндәге эчтәлекле $13^1$ пункты өстәргә:

«$13^1$. Вәкаләтле органның һәм Татарстан Республикасы Нотариаль палатасының нотариусларның дәүләт системасы кысаларында бушлай башкарылган нотариаль гамәлләре өчен түләүне компенсацияләгәндә үзара хезмәттәшлеге Федераль законда билгеләнгән тәртиптә башкарыла.».

2. Әлеге Указ 2024 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Рәисе** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ РӘИСЕ АДМИНИСТРАЦИЯСЕ
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2023 ел, 25 декабрь
№ 906